# Габдулла  Тукай




*И  мөкаддәс, моңлы*
*сазым,*
*Уйнадың  син ник*
*бик аз…*



*Татар халык шагыйре Габдулла Тукай 1886 елның 14 апрелендә элекке Казан губернасы Мәңгәр волосте Кушлавыч авылында туа. Кечкенәдән ятим калган Габдулла, кулдан-кулга йөреп, балачагын Сасна, Өчиле, Кырлай авылларында уздыра.*

# *Шагыйрьнең  әтисе Мөхәммәтгариф йорты*



*Габдулла  туып дүрт ай ярым үткәч, Мөхәммәтгариф хәзрәт үлеп китә. Тол калган Мәмдүдәне (Габдулланың әнисен) Сасна мулласына кияүгә бирәләр. Шагыйрьнең газаплы, авыр тормышы башлана.*


# Өчиле авылы



*«Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга, мине җыласам – юатучы, иркәләним дисәм – сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә – кызганучы бер дә булмаган, мине эткәннәр дә тöрткәннәр...*

*(Г.Тукай “Исемдә калганнар”)*

# Кырлай авылы, Кырлай урманы…



1892 елның июнендә малай Кырлай авылына, Сәгъди абзый белән Зөһрә апа гаиләсенә килеп керә.

Кырлайдагы тормышы яшь Тукайның күңлендә иң җылы истәлекләр калдыра.





Кырлай мохите Тукай шигъриятендә күп кенә мотив һәм темалар өчен чыганак булып тора. “Шүрәле” әкияте үзе генә дә Кырлай истәлегенң гүзәл бер шигъри һәйкәле итеп санала.











*Уральскидә. Гәлиаскәр Усманов өйе.*

*1895 елда Габдулла Тукай Уральскига атасының сеңелесе Газизә Забирова тәрбиясенә алына. Биредә ул заманына күрә алдынгы булып саналган "Мотыйгия" мәдрәсәсенә урнаштырыла. Тукайның тәүге иҗади талпынулары шушы мәдрәсәдә укыган чорга бәйле .*



*1905 елгы революция Уральск шәһәрен дә тетрәтте. “Фикер”, “Әлгасрел-җәдит”, “Уклар” исемле беренче татар телендә гәҗитә һәм журналлар чыга башлый. Тукай шул басмаларда хәреф җыючы, төзәтүче, хәбәр җыючы, хәтта мөхәррир булып та эшләде.*






Г.Тукайның шәхси әйберләре





1907 елның көзендә Габдулла Тукай туган якларына кайта һәм Казанга килеп урнаша: “Әл - ислах” исемле журналда һәм “Китап” нәшриятында җиң сызганып эшләүчеләрдән берсе булып китә.

*Сәгыйть Рәмиевка язган хатында Тукай болай дигән:*

*«Мин поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә... ».*

# **Истәлекләр:**

*...Яланбаш, кара күзлектән, өстенә казакимы, җөббәме, иске генә бер нәрсә кигән, аягында тузган кара буркалы шыксыз гына бер малай, минем «ие» дигән сүземне дә көтмичә, каршымда, өстәл кырыенда, буш торган урындыкка килеп тә утырды…*

*(Сәгыйть Рәмиев)*

*Кыскарак буйлы, чандыр гәүдәле бу кунакның йөзе әүвәл караштa аны баласымак итеп күрсәтә. Өстенә кигән казаки дисәң — казаки түгел, җилән дисәң—җилән түгел бер нәрсәсе һәм яланбашлыгы аны шул «гасырның ислахчы шәкерте» итеп таныта иде …*

*(Әмирхан Фатих)*





**Әстерхан**

*1912 елның язында Габдулла Тукай Петербургка бара. Кымыз белән дәвалану максаты белән Уфа һәм Троицк якларында сәфәрдә була.*

*1911 елның апрелендә кымыз белән дәваланырга дип татар зыялылары чакыруы буенча Әстерханга сәяхәт кыла.*



**Уфа**

*Шагыйрьнең саулыгы көннән-көн начарлана бара. 1913 елның апрельнең 15-дә 27 яшендә Габдулла Тукай якты дөньядан мәңгелеккә күчә. Никадәр генә газаплар кичерсә дә, бу фаҗигале, кыска гомер юлын горур атлап уза.*








*Шагыйрь иҗтимагый прогресска хезмәт итүне үзенең граждaнлык бурычы итеп санады; кыска гына гомер юлында күпкырлы иҗаты белән татар культурасы тарихында яңа эпоха ачты.*

# Габдулла Тукайга багышланган һәйкәлләр








Габдулла Тукай урамы



Габдулла Тукай исемендәге теплоход



Габдулла Тукай мәйданы



Габдулла Тукай премиясе